РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

28 апрель 2017 ел № 3-19

**«Татарстан Республикасының Буа муниципаль районында Дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру барышы турында»**

«Буа муниципаль районында Татарстан Республикасы Дәүләт милли сәясәте концепциясен гамәлгә ашыру барышы турында» мәгълүмат тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы билгеләп үткәнчә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, халыкның тулы хокуклы социаль-икътисадый, мәдәни һәм милли үсешен тәэмин итү өчен шартлар тудырылган. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программасы, районда гамәлгә ашырыла торган башка муниципаль программалар, Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын гамәлгә ашыру чаралары планы, Татарстан Республикасы телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт программасын үтәү район территориясендә яшәүче барлык халыкларның мәнфәгатьләрен яклауга, аларның тормыш эшчәнлеге һәм районның иҗтимагый-сәяси тормышында катнашу өчен тигез шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Районда сәяси вазгыять тотрыклылык, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр белән характерлана. Югарыда бәян ителгәннән чыгып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды

1. Татарстан Республикасының дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә иң мөһим юнәлешләрнең берсе дип санарга.
2. Социаль-икътисадый программалар әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда, мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау, кадрлар сәясәте өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашырганда, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, муниципаль учреждениеләргә һәм оешмаларга милли мөнәсәбәтләр, милләтара хезмәттәшлек өлкәсендә конкрет бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасының милли сәясәте концепциясе белән җитәкчелек итәргә, Татарстан Республикасының дәүләт милли сәясәте концепциясен киң яктыртуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгының
беренче урынбасары И.Ф. Еремеев